КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 март г.Казань № 192

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы;

2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 20 июль, 605 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 10 июнь, 543 нче; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче, 2023 ел, 3июль, 779 нчы, 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче, 2023 ел, 15 декабрь, 1621 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

2 пунктның 2.2 пунктчасының 2 нче графасында «сиделка» сүзен «карау буенча ярдәмче» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның 4.2 пунктчасының 2 нче графасында «сиделка» сүзен «карау буенча ярдәмче» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 5.2 пунктчасының 2 нче графасында «һәм «сиделка» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктның 9.2 пунктчасының 2 нче графасында «сиделка» сүзен «карау буенча ярдәмче» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның 10.2 пунктчасының 2 нче графасында «сиделка» сүзен «карау буенча ярдәмче» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның «Сиделка (карау буенча ярдәмче)» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Карау буенча ярдәмче | һөнәри белем бирүнең төп программалары – хезмәткәрләр вазифалары буенча һөнәри әзерләү программалары | бала караучы | 15 279». |

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин